СОВЕТ ПЕЧИЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ПЕЧИЩИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

РЕШЕНИЕ | КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

17.11.2023 | с. Печищи | № 37-193

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге  Печищи торак пункты территориясендә гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Печищи авыл  җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,  Печищи торак пунктының бер өлешенең халык төркеме инициативасын карап

Югары Ослан муниципаль районы
Печищи  авыл җирлеге  Советы
карар итте:

1. 2023 елның 04 декабренә Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге  Печищи торак пунктында  гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге Печищи торак пункты  территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 13334 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән сез килешәсезме:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге  Печищи торак пунктында  авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын 2023 елның 4 декабрендә Печищи авылы Декабристлар ур., 35А йорты (авыл җирлеге бинасы) адресы буенча 14.00 сәгатьтә уздырырга.

4. Печищи авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Печищи авыл җирлеге башлыгы Е.В. Рахматулина